

Татар халкы тарихында лаеклы урын алган җәvһәр ул гармун. Асыл ир-егетләр илен-җирен саклап яуга киткәндә дә жилкәсенә гармунын салган, аны тартып кайгы-сагышын баскан. Мәхәббәт шаһиты да ул гармун, сойгән ярларга тирән хисләрне житкерvче дә. Хәтерләсәгез, һәрбер авылда охшаш кvренеш – яшьләр урам буйлап гармун тотып жырлап vтә. Кvпме йорәкләрне кавыштырган бит ул. Кынгыраулы атлар белән авылга килен тошкәндә дә ин тvрдә гармунчы – затлы кеше булган. Чонки алар кеше кvнелен тәрбияләvчеләр.      Заманалар vзгәреш кичерә. Әмма гармунчыларнын абруе кимеми. Мән-гелек кыйммәтләрне саклаучыларга халык баш ия, гармун моны безне якынайта, берләштерә. Шуна да кvп кенә тобәкләрдә, шәһәр-районнарда әлеге уен коралын зурлап торле бәйрәм чаралары vтә. Мордовиянен Ләмберә районы да талантларга vтә бай як. Һәрбер авыл жирлеге оста, сәләтле гармунчылары, баянчылары белән чын-чынлап мактана ала. Мин дә шундый гармунчыларнын берсе белән таныштым. Ул – «Уйна, гармун» район һәм республика конкурслары лауреаты, Тvбән Новгород шәһәрендә тобәкара фестивальләрдә катнашучы «Саранск шәһәр округы мәдәният сарае» гармунчысы Зыя Зәкәрья улы Максутов.

Зыя Зәкәрья улы Ләмберә районы Татар Свербейка авылында бердән-бер гармунчы булган жиде балалы (оч ул һәм дvрт кыз) Зәкәрья Ильяс улы гаиләсендә туа. Гаиләдә абыйсы белән икәv этиләреннән гармунда уйнарга ойрәнеп калалар. Гармунда ничә яшьтән уйнавы турында сорадым. Ул, истәлекләрен янартып:

- Мин жиде яшьтән гармунда уйныйм, ә инде дvртенче, әллә бишенче сыйныфларда укыганда туйларда мостәкыйль уйный башладым. Ул заманда гармунчылар аз, ә туйлар кvп иде, шуна кvрә ике ай алдан чакырып куя иделәр гармунчыны. Әтием бер авыл туенда уйнаса, мин – икенчесендә. Шулай, бер сенелем Казанга киявгә чыкты. Мин туйда гармун уйныйм: гармун тавышын ишетәләр, ә гармунчысын кvрмиләр. Минем буем кечкенә булганга зур гармун артыннан кvренми дә идем, янтаудан – кырыйдан мине килеп карадылар. Колеп: аннары ястыкка утырттылар – барыбер этием Горький шәһәреннән алып биргән беренче зур “Беларусь” исемле гармун артыннан кvренмәдем.



[illegible]